**СОВЕТ ВЫСОКОГОРСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ ВЫСОКОГОРСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**
422701, Республика Татарстан, Высокогорский район,
с. Высокая Гора, ул. Б. Красная, 113А

**РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН БИЕКТАУ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БИЕКТАУ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ**
422701, Татарстан Республикасы, Биектау районы,
Биектау авылы, Зур Кызыл ур., 113А

Тел./факс: +7(84365) 74-7-79, e-mail: Vgor.Vsg@tatar.ru

**РЕШЕНИЕ**
19.11.2024г.

**КАРАР**
№405

Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Биектау авыл җирлеге Советының 2015 елның 15 октябрендәге 12 нче номерлы «Физик затлар мөлкәтенә салым турында» карарына үзгәрешләр кертү турында

Россия Федерациясе Салым кодексының 32 бүлеге, 2014 елның 30 октябрендәге 82- ТРЗ номерлы «Салым салу объектларының кадастр бәясеннән чыгып, физик затлар мөлкәтенә салым буенча салым базасын билгеләү тәртибен Татарстан Республикасы территориясендә куллана башлауның бердәм датасын билгеләү турында» Татарстан Республикасы Законы нигезендә, Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Биектау авыл җирлеге Советы

**КАРАР КЫЛДЫ:**

1. Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Биектау авыл җирлеге Советының 2015 елның 15 октябрендәге 12 нче номерлы «Физик затлар мөлкәтенә салым турында» карарына (2018 елның 11 нче маендагы 364 нче номерлы, 2018 елның 13 сентябрендәге 410 нчы номерлы, 2018 елның 28 нче декабрендәге 464 нче номерлы, 2022 елның 22 ноябрендәге 246 нчы номерлы, 2023 елның 19 сентябрендәге 307 нче номерлы, 2023 елның 16 ноябрендәге 317 нче номерлы Совет карарлары редакциясендә) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 2 пунктның 4 пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«4) 2,5 процент:

һәркайсының кадастр бәясе 300 миллион сумнан артып киткән салым салу объектларына карата;»

1.2. 2 пунктның 6 пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2025-2027 елларда 1,2 процент, 2028 елдан 2%:

Россия Федерациясе Салым кодексының 378.2 статьясындагы 7 пункты нигезендә билгеләнә торган исемлеккә кертелгән салым салу объектларына;
Россия Федерациясе Салым кодексының 378.2 статьясындагы 10 пунктының икенче абзацында каралган салым салу объектларына карата.»

2. Әлеге карар законлы көченә 2025 елның 1 гыйнварыннан, әмма ул рәсми рәвештә игълан ителгән көннән кимендә бер ай узгач керә.

3. Әлеге карарны «Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең Интернет челтәрендәге рәсми сайтында https://vysokaya-gora.tatarstan.ru/ адрес буенча һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында http://pravo.tatarstan.ru урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә.

Совет рәисе,
Биектау авыл җирлеге башлыгы А.А. Хабибуллин